| МИНИСТЕРСТВО<br>ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И<br>СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ<br>РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ<br>БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ<br>СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.11.2020 г.Казань № 791

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 4 декаберендә 7116 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 19 октябрендәге 962 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфаты ярашлы булуы турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфаты ярашлы булуы турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 19 октябрендәге 962 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 31.05.2019 №414, 16.11.2019 №1042, 13.07.2020 №497, 28.09.2020 №675 боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре

белән) белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфаты ярашлы булуы турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр в.б. Р.Ф. Вәлиуллов

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 13 ноябрендәге 791 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфаты ярашлы булуы турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 19 октябрендәге 962 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфаты ярашлы булуы турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлекнең 1.2 пунктындагы унберенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

2 бүлектә:

2.1 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү»;

2.4 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасының дүртенче абзацында «социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән хезмәттәшлек мәсьәләләрен алып баручы Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары» сүзләрен «министр» сүзләренә алмаштырырга;

2.4 пунктта «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасының сигезенче абзацында «, шулай ук салымнар һәм җыемнар, Россия Федерациясе законнарында каралган башка мәҗбүри түләүләр буенча бурыч булмаганлыгын раслый торган документлар» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.6 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының өченче абзацын көчен югалткан дип танырга;

2.8 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының тугызынчы абзацын көчен югалткан дип танырга;

2.15 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының алтынчы һәм унтугызынчы абзацында «(http://uslugi.tatar.ru/)» сүзләрен «(http://uslugi.tatarstan.ru/)» сүзләре белән алмаштырырга;

3 нче бүлектә:

3.3.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Административ процедураны үтәү вакыты: гариза һәм документлар кергән көнне.

Административ процедураның нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документларны (документлар күчермәләрен) министр урынбасарына җибәрү.»;

3.3.4 пунктта:

беренче абзацта «3.1.3 пунктта» сүзләрен «3.1.2 пунктта» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Административ процедураны үтәү вакыты: гариза һәм документлар кергән көнне.

Административ процедураның нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны (документларның күчермәләрен) җаваплы структур бүлекчәгә җибәрү»;

3.5.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Бүлекнең җаваплы заты ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү турында гариза тапшырылганчыга кадәр ике ел эчендә социаль юнәлешле коммерциясез оешманың 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә намуссыз тәэминатчылар (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмавы турында белешмәләр (документлар) бирү турында электрон формада рәсми мөрәҗәгать җибәрә (Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе).

Ведомствоара мөрәҗәгать электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешентә формалаштырыла һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы (алга таба – ВЭХС) каналлары буенча җибәрелә.

Ведомствоара электрон мөрәҗәгатьне электрон документ рәвешендә формалаштыру һәм ВЭХС каналлары буенча җибәрүнең техник мөмкинлекләре булмаганда, ведомствоара мөрәҗәгать кәгазьдә почта аша, бер үк вакытта почта аша яисә курьер ярдәмендә җиткерү юлы белән факс буенча җибәрелә.

Ведомствоара мөрәҗәгать 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7.2 статьясы таләпләре нигезендә формалаштырыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедураны үтәү вакыты: гаризаны теркәгәннән соң 3 эш көне.

Процедураның нәтиҗәсе: ведомствоара рәсми мөрәҗәгать формалаштыру һәм җибәрү.»;

3.5.3 пунктында:

беренче абзацта «күрсәтелгән ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр» сүзләрен «күрсәтелгән ведомствоара рәсми мөрәҗәгать» сүзләренә, «килгән» сүзен «алынган» сүзенә алмаштырырга;

икенче абзацта «рәсми мөрәҗәгатьләр» сүзләрен «рәсми мөрәҗәгать» сүзләренә алмаштырырга;

3.7 пунктта:

икенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

дүртенче абзацта «министрга (министр урынбасарына)» сүзләрен «министр урынбасарына» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министр урынбасары белән килештерелгән бәяләмә проекты министрга җибәрелә.»;

алтынчы абзацта «министрга (министр урынбасарына)» сүзләрен «министр урынбасарына» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министр урынбасары белән килештерелгән бәяләмәне бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү проекты министрга җибәрелә.»;

тугызынчы абзацта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына» сүзләрен «министрга» сүзенә алмаштырырга;

3.8.1 пунктта «Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән хезмәттәшлек мәсьәләләрен алып баручы Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары» сүзләрен «министр белән» сүзләренә алмаштырырга;

3.8.3 пунктның өченче абзацында «социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән хезмәттәшлек мәсьәләләрен алып баручы Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары» сүзләрен «министр белән» сүзләренә алмаштырырга;

3.9.3 пунктта:

дүртенче абзацта «министрга (министр урынбасарына)» сүзләрен «министр урынбасарына» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министр урынбасары белән килештерелгән бәяләмә проекты (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү проекты) министрга җибәрелә.»;

3.9.4 пунктта:

беренче абзацта «Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән хезмәттәшлек мәсьәләләрен алып баручы Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары» сүзләрен «министр белән» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән хезмәттәшлек мәсьәләләрен алып баручы Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары» сүзләрен «министр белән» сүзләренә алмаштырырга;

3.9.5 пунктның өченче абзацында «социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән хезмәттәшлек мәсьәләләрен алып баручы Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары» сүзләрен «министр белән» сүзләренә алмаштырырга;

5 бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм

гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

Регламентка 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфаты ярашлы булуы турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Формасы

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән белдерү

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатына үткәрелгән бәяләү нәтиҗәләре буенча социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәт сыйфатынын ярашлылыгы турында бәяләмә бирүдән баш тарта:

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

(социаль юнәлешле коммерциясез оешманың тулы атамасы һәм төп дәүләт теркәвенә алу номеры)

түбәндәге иҗтимагый файдалы хезмәтләр:

________________________________________________________________;

________________________________________________________________;

________________________________________________________________

(иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең атамасы)

Әлеге иҗтимагый файдалы хезмәтләр иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына түбәндәге нигезләр буенча туры килми:

________________________________________________________________;

________________________________________________________________;

________________________________________________________________.

Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры _______________________ ____________________

имза ФИА

«____»__________20___ел;

Административ регламентка кушымтаны (белешмәлекне) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын бәяләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Дәүләт хезмәтен күрсәтү һәм аның үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру өчен җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының структур бүлекчәсе аталышы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| Министр | | (843) 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | | (843) 557-20-03 | Klara.Tazetdinova@tatar.ru |
| Бүлек җитәкчесе | һөнәргә укыту һәм һөнәри юнәлеш бирү бүлеге | (843) 557-20-90 | Sofya.Tonkonog@tatar.ru |
| Бүлек җитәкчесе | хезмәт базарын мониторинглау һәм дәүләт хезмәтләре бүлеге | (843) 557-20-93 | Irina.Posokova@tatar.ru |
| Бүлек | социаль якланмаган | (843) 557-20-73 | Elena.Kibardina@tatar.ru |

| | | | |
|---|---|---|---|
| җитәкчесе | категорияләр өчен эш урыннары оештыру бүлеге | | |
| Бүлек җитәкчесе | эш башкару бүлеге | (843) 557-21-01 | Svetlana.Novikova@tatar.ru |

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе җитәкчесе | (843) 264-77-29 | pisma@tatar.ru". |